**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 март № 141

г. Казань

2017 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында

Тискәре табигый-климат шартлары барлыкка килү чорында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында (алга таба – төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары) конструкция элементларының күтәреп тору сәләте кимүгә юл куймау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге чорда кертергә:

2017 елның 15 апреленнән 14 маена кадәр, төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларыннан уза торган, күчәргә яки күчәрләр төркеменә (арбага) төшә торган рөхсәт ителгән авырлыклары әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән иң чик күрсәткечләрдән артып киткән йөкле һәм йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (алга таба – язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү);

2017 елның 20 маеннан алып 31 августына кадәр, «Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе билгеләнгән тәртиптә бирә торган мәгълүматларга таянып, һаваның көндезге температурасы күрсәткечләре 32°С тан югарырак булганда асфальт-бетон түшәлгән төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыра торган транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (алга таба – җәйге чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацта билгеләнгән чорга транспорт чарасының һәр күчәренә яки күчәрләр төркеменә (арба) төшә торган рөхсәт ителгән чик авырлыкларның түбәндәге күрсәткечләрен билгеләргә:

берле күчәрлегә – 6,0 тонна;

ике күчәрле арбаларга – һәр күчәргә 5,0 тонна;

өч күчәрле арбаларга – һәр күчәргә 4,0 тонна.

3. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

язгы чорда – «Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә күздә тотылган 8.20.1 һәм 8.20.2 «Транспорт чарасы арбасы төре» дигән өстәмә мәгълүмат билгеләре (табличкалар) белән 3.12 «Транспорт чарасы күчәренә төшә торган авырлыкны чикләү» юл билгесен урнаштыру юлы белән;

«Татарстан Республикасының гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе мәгълүматларына таянып, һаваның көндезге температурасы күрсәткече 32°С тан югарырак булган җәйге чорда – «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «Хәрәкәтнең махсус шартлары» графасына төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөк ташуны гамәлгә ашыра торган транспорт чаралары, күчәрләренә төшә торган авырлык Россия Федерациясе территориясендә билгеләнгән күчәргә төшә торган авырлыктан артып киткән транспорт чаралары хәрәкәтенә махсус рөхсәтне, түбәндәге эчтәлекле язу кертү юлы белән: «җәйге чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертелгәндә хәрәкәт 22.00 сәгатьтән алып 10.00 сәгатькә кадәр рөхсәт ителә»;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә таянып.

4. Тәкъдим итәргә:

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе тарафыннан юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген тормышка ашырганда, шул исәптән транспорт чараларының авырлыгын тикшерүне гамәлгә ашырганда авырлыкны һәм габаритны тикшерү пунктларында транспорт чараларын үлчәүне тәэмин итәргә;

«Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә – Татарстан Республикасында җәйге чорда көндезге вакытта була торган һәм фаразланган һава температурасы турында Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенә, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә мәгълүмат бирергә.

5. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2017 елның 15 мартына кадәр язгы һәм җәйге чорларда вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга;

«Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе мәгълүматларына таянып, һаваның көндезге температурасы күрсәткечләре 32°С тан югарырак булганда Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә юл хәрәкәтендә катнашучыларның җәйге чорда хәрәкәт итүне вакытлыча чикләү шартларын үтәүне тикшерү зарурлыгы турында мәгълүмати хат җибәрергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2016 ел, 14 март, 137 нче карары үз көчен югалткан дип таныrга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\141.docx